**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
САРМАНОВСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
«ЛЕШЕВ-ТАМАКСКОЕ СЕЛЬСКОЕ
ПОСЕЛЕНИЕ»**
**ул. Молодежная, д. 1 а,
с. Лешев Тамак, 423353.
Телефон: (85559) 4-13-24
E-mail: Levtam.Sar@tatar.ru**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЛӘШӘҮ ТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
**Яшьләр урамы, 1 а йорт,
Ләшәү Тамак авылы, 423353.
Телефон: (85559) 4-13-24
E-mail: Levtam.Sar@tatar.ru**

**ОГРН 1061687002486 ИНН/КПП 1636005447/163601001**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

18.03.2019ел №8

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы "Ләшәү Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Ләшәү Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә 2018 елның 18 ноябрендәге 187 номерлы җирле референдумда кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру максатларында Ләшәү Тамак авыл җирлеге башкарма комитеты карар чыгарды.

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчасы җыю тәртибен (1 нче кушымта) расларга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында " (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы»муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Ләшәү Тамак авыл җирлеге башкама
комитеты җитәкчесе И.З.Хабибуллин

Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак
авыл җирлеге башкарма
комитетының 2019елның
18 мартындагы 1 номерлы
карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе

1. Әлеге тэртип Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү 18 яшькә җиткән һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлеге территориясендә теркәлгән гражданнар тарафыннан, 1 группа инвалидлардан, хәрби хезмәт узучы хезмәткәрләрдән, көндезге бүлектә белем алучы студентлар тыш һәм аларның саны авыл җирлегендә яшәүчеләрнең гомуми саныннан 30 проценттан артмаска тиеш, 2019 нчы елның 31 мартына кадәр, җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашуына һәм тавыш биргәндә алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләргә бәйсез рәвештә түләнә.

4. Бер тапкыр түләү турында хәбәр итү (белдерү) бланкы Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында халыкка хәбәр итү юлы белән, шулай ук почта элемтәсе аша тапшыру яки җибәрү юлы белән гражданнар игътибарына җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (белдерүдә) гражданнарның үзара салым акчаларын күчерү реквизитлары, тулы яисә киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы (2 нче кушымта) күрсәтелә.

5. Гражданнарның үзара салым акчалары Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык хезмәте идарәсенең лицевой счетына (Сарман муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы) күчерелә.

6. Гражданнар тарафыннан түләү физик затлар кушуы буенча исәп-хисап ясау һәм почта аша күчерүгә хокуклы оешмалар аша, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша (сылтама буенча) башкарыла https://uslugi.tatarstan.ru/.

7. Түләү квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаучы башка документлар түләү фактын раслау булып торалар.

8. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары закон тпрафыннан билгеләнгән тәртиптә түләтерелә.

Сарман муниципаль районы
Ләшәү Тамак
авыл җирлеге башкарма
комитетының 2019 елның
18мартындагы 8 номерлы
карарына 1 нче кушымта

Ләшәү Тамак авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган
түләү кертү турында
БЕЛДЕРҮ КӘГАЗЕ№_____

Түләүченең Ф.И.Ә.И
__________________________________________________________________________
Адресы: ____________________________________________________________
Нигезләмә ________________________________________________________
Сезгә _______________________ кадәрле вакыт эчендә_______________________
чараны гамәлгә ашыру буенча __________ сум күләмендә бер тапкыр түләнә торган
түләүне түбәндәге реквизитларга күчерергә кирәк:
Кабул итүче як банкы БИК ___________________________________
Кабул итеп алучы Сч. № ________________________________________
ИНН __________________________________________
КПП __________________________________________
КБК _______________ ОКАТО ____________ ______
Түләүнең билгеләнеше
__________________________________________________________________________

Җитәкче _________________ ________________________________________
М.У. (имза) (тулысынча язылыш)

- - - - - - - - - - - - - - - - - **кисеп алу сызыгы** - - - - - - - - - - - - - -

Ләшәү Тамак авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган
түләүне ______________ сум күләмендә түләү турында №______ белдерү кәгазе
Түләүченең Ф.И.А.И. ____________________________________________________
Адресы:___________________________________________________________________
__________________________________________________________________________
Кабул ителде «__» _______________ 20__ ел. ________________________________
(түләүченең
имзасы/фамилиясе)

*Искәрмә. Белдерү кәгазе түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта, түләү кәгазе өлеше(отрывной корешок) тутырыла һәм Ләшәү Тамак авыл җирлеге башкарма комитетында кала*